ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2021 № 1707

Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 июлендәге 1070 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының милли рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климаты торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 21 октябрендәге 991 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 1070 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 пунктындагы 10 пунктчасына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) капиталь төзелеш объектын технологик тоташтыру эшләрен үткәргән очракта төзелешкә рөхсәт, җир кишәрлегеннән файдалануга (челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру очракларыннан тыш), ризалык (рөхсәт) булмау.».

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов